# Нәрсә ул яхшы?
# Нәрсә ул начар?



**Тырыш бала эш сөя,**
**Китапка күңел сала.**
**Андыйны бик**
**мактыйлар,**
**Ул- яхшы бала,**
**диләр.**




Бусы кергән пычракка,
Шуңа үзе шатлана.
Андыйны яратмыйлар,
Ул- начар, шапшак бала.



Бусы юа галошын,
Пимасын үзе сөртә;
Нәни генә булса да,
Ул үзен яхшы йөртә.





# «Тылсымлы сүзләр»



- Рәхмәт!
- Зинһар өчен!
- Хәерле иртә!
- Хәерле көн!
- Хәерле кич!
- Исәнмесез!
- Рәхим итегез!
- Сау булыгыз!
- Исән булыгыз!



**Җиргә төшкәч бияләе,**
**Гафур алып биргән иде,**
**Динә аңа:**
**-Рәхмәт, -диде.**
**Малайның да җылы сүзгә кәеф килде.**
**Елмайды да:**
**-Рәхмәтеңә рәхмәт!-диде.**
**Кыз җавапсыз калсын диме?**
**Җавап бирде:**
**-Рәхмәтемә рәхмәт өчен рәхмәт инде!**
**Малай аңа башын иде:**
**-Рәхмәтемә рәхмәт өчен рәхмәтеңә рәхмәт,-диде.**
**Динә көлде. Бик күңелле, рәхәт иде.**
**...Җиргә төшкән бияләйгә рәхмәт инде. (Шәүкәт Галиев)**

Әбисе бәлеш пешергәч,
Әй сыйланган соң Әхмәт.
Әллә телен йоткан инде,
Әйтергә оныткан...

рәхмәт.

Әбиебез өйнең нуры,
Ул һәммәбездән олы.
Анын кулы шундый йомшак,
Анын куллары...

җылы.

Бу дөньяда иң чибәре -
Минем әни! - ди Артур.
Бүген дә елмаеп әйтте:
Син, әни, нинди ...

матур.



# “Балага”

- **Кешеләрне ярат,**
- **әйбәт гадәтле бул,**
- **Сабыйларны кыерсытма – әдәпле бул!**
- **Ихтирам ит олыларны, кечеләрне!**
- **Очрашканда исәнләш син –**
- **телең калмас,**
- **Сәламеңне алмаса, тик**
- **надан алмас.**
- **Ата-ана хакын хакла – тел тидермә,**
- **Тыңлаучан бул, каршы әйтеп**
- **җан көйдермә.**
- **Тәртибең дә, укуың да булса үрнәк,**
- **Үзеңә дә килер шулчак**
- **кадер – хөрмәт.**
- *Мөхәммәт Закиров*